УДК 373.3

***Л.Г. Гыйләҗева,***
***Г.В. Һадиева***

# ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЛАРЫ: БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘПТӘ КОМПЛЕКСЛЫ ЭШЛӘР

Комплексные работы на татарском языке для 1 класса позволяют на основе текста определить понимание прочитанного, а также оценить предметные результаты по математике, русскому языку и окружающему миру и выявить уровень сформированности универсальных учебных действий. Статья посвящена вопросам оценивания знаний и умений учащихся 1 класса по Федеральному образовательному стандарту начального общего образования (ФГОС НОО). Использование данных материалов в урочной и внеурочной деятельности позволит выявить сформированность предметных, метапредметных и личностных результатов.

**Ключевые слова:** комплексные работы, предметные результаты, метапредметные результаты (универсальные учебные действия), личностные результаты, стартовый и итоговый контроль, система оценивания.

Соңгы ун ел эчендә җәмгыятьтә белем бирүнең максатларын һәм аны тормышка ашыруның юлларын күзаллау кардиналь рәвештә үзгәрде. Нигездә, белем системасын тәкъдим итү – билгеле бер нәтиҗә алу максаты белән белем бирүдә актив эшчәнлеккә күчү, аерым бер уку предметларын үзләштергәндә катлаулы тормыш ситуацияләрен предметара бәйләнеш, белем һәм күнекмәләргә ия булу барышында укытучы белән укучы арасындагы хезмәттәшлек, укытуның эчтәлеген һәм ысулларын сайлаганда, укучының актив катнашу процессы [Метапредметные результаты, с. 9]. Мәктәп укучыларында гомумуку күнекмәләрен формалаштыру бүгенге көндә тиз һәм сыйфатлы белем бирүдә перспектив юл булып тора.

Саналып кителгән компонентлар универсаль уку гамәлләрен (*алга таба УУГ*) үстерү концепциясендә күрсәтелгән [Как проектировать..., с. 7]. Шуңа күрә укучыларның яңа белем бирү баскычына әзерлек дәрәҗәләрен белем һәм күнекмәләр нигезендә генә түгел, ә УУГнең төп төрләрен формалаштыру базасында бәяләргә кирәк. Белем бирү системасының төрле баскычлары дәвамлылыгының нигезе – «белем ала белү»не формалаштыру.

Бүгенге көндә мәгариф системасында мөһим нәтиҗәләрнең берсе булып, укучыны «белем ала белү»гә өйрәтә торган һәм үзүсеш, үзтәрбия сәләтен үстерүгә юнәлтелгән метапредмет нәтиҗәләре санала [Метапредметные результаты, с. 15]. Федераль дәүләт белем бирү стандартлары (*алга таба ФДБС*) укучыда УУГ формалаштыруны максат итеп куя. Билгеле булганча,

алар дәрестә һәм дәрестән тыш эшчәнлек нәтиҗәсендә предмет материалына нигезләнеп алып барыла.

Универсаль уку гамәлләрен үстерү концепциясе эшчәнлеккә системалы якын килүне күздә тота. Киң мәгънәдә «универсаль уку гамәлләре» термины «белем ала белү» мәгънәсен аңлата, ягъни субъектның аңлы һәм актив рәвештә яңа социаль тәҗрибә алу юлы белән үсешкә һәм камилләшүгә сәләтле булуын белдерә. Тар мәгънәдә исә бу терминны укучыларның мөстәкыйль рәвештә яңа белемнәрне үзләштерү, күнекмәләрне формалаштыруны тәэмин итә торган эшчәнлек ысулларының җыелмасы дип билгеләп була.

ФДБСның төп үзенчәлекләренең берсе – **яңа бәяләү системасы.** Стандарт таләбеннән чыгып, укучыларның предмет буенча белемнәре генә түгел, ә УУГ формалашу һәм аның шәхескә кагылышлы нәтиҗәләре дә исәпкә алына. Нәтиҗәдә эчке контроль системасының ике состав өлеше билгеләнә: педагогның контроль-бәяләү эшчәнлеге һәм укучыларның үз контроль-бәяләү эшчәнлеге [Хәмитова, б. 6]. Шул уңайдан заманча мәктәптә укучыларда метапредмет нәтиҗәләрен бәяләүдә предметара нигезгә корылган **комплекслы эшләр** аеруча әһәмиятле. Комплекслы эшләр – башлангыч мәктәптә метапредмет нәтиҗәләренә ирешүне бәяләүне формалаштыру чарасы, тәкъдим ителгән текст өстендә эшләү аркылы «Әдәби уку», «Татар теле», «Рус теле», «Математика», «Әйләнә-тирә дөнья» һ.б. предметларга караган биремнәр системасы ул. Мондый тип эшләрдәге биремнәр системасы икенче буын стандартлары нигезендә билгеле бер белемнең үзләштерелүен тикшерүгә генә түгел, ә беренче сыйныф укучысының тупланган белем, формалаштырылган күнекмәләр һәм УУГ нигезендә уку һәм гамәли мәсьәләләрне чишә белүен тикшерүгә дә юнәлдерелгән [Сизонова, с. 163].

Бүгенге көнгә кадәр мәгариф системасында татар телендә нәшер ителгән комплекслы эшләр бөтенләй юк. Шушы ихтыяҗны исәпкә алып, «Өйрәтү характерындагы комплекслы эшләр: 1 нче сыйныф» дип аталган ярдәмлек (кулъязма формасында) төзелде.

Ярдәмлектә нигездә өйрәтү характерындагы комплекслы эшләр урын алган. Алар татар мәктәпләрендә кулланыла торган дәреслекләрнең укыту-методик системасына нигезләнеп төзелде. Өйрәтү характерындагы әлеге хезмәтне укытучылар төрле предмет кысаларында куллана ала.

Комплекслы эшләрне 3 нче чирек ахырында һәм 4 нче чиректә үткәрергә тәкъдим ителә. Ярдәмлектә урын алган вариантларның барысын да эшләү мәҗбүри түгел, укытучы үзе теләгәнен сайлап алырга яки әтиәниләргә балалар белән аерым эшләү өчен тәкъдим итәргә мөмкин. Индивидуаль эшләгәндә материалны авыр үзләштерүче балага өлкәннәрнең ярдәме мөһим. Кулланманы шулай ук укучылар өчен өстәмә дидактик материал һәм метапредмет күнекмәләрен

формалаштыру һәм йомгаклау эшенә әзерләү өчен дә файдаланырга мөмкин.

Ярдәмлектә өйрәтү характерындагы комплекслы эшләр 20 вариантта тәкъдим ителде. Биремнәр халык авыз иҗаты, татар һәм рус язучыларының әдәби әсәрләренә нигезләнеп формалаштырылды. Текстлар төрле эчтәлектә һәм укучыларның яшь үзенчәлегеннән чыгып яраклаштырылды.

Комплекслы эшләр, укучыларда «Татар теле», «Әдәби уку», «Рус теле», «Математика», «Әйләнә-тирә дөнья», «Сынлы сәнгать» предметлары буенча нәтиҗәләр формалаштыру белән беррәттән, шәхескә кагылышлы (әдәп-әхлак нормаларын үзләштерү, үзен тормышта лаек шәхес итеп тоту, ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләү һ.б.) һәм метапредмет нәтиҗәләренә карап (танып белү, коммуникатив һәм регулятив УУГ) 4 төр типик биремнәр рәвешендә тәкъдим ителде.

Ярдәмлек белән эшләү барышында беренче сыйныф укучысында түбәндәге белем һәм күнекмәләрне үстерү максат итеп алынды. Уку өлкәсендә: уку техникасы һәм күнекмәсе, «эчтән уку» күнекмәсен формалаштыру, текстта ориентлаша белү (текстка кагылышлы сорауларга җавап бирә белү, текст эзлеклелеген билгеләү, авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, текстның идея эчтәлеге белән икенче бер текст эчтәлеге арасында параллель үткәрә белү), инструкцияне укып аңлый белү, биремнән чыгып, тексттан кирәкле булган мәгълүматны сайлап ала белү, тексттагы мәгълүматны биремнәр системасындагы мәгълүмат белән бәйли белү, текст һәм мәгълүмат белән эшли белү, текст эчтәлегенә карата үз фикерен формалаштыра һәм әйтә белү, тестлар белән эшли белү.

Тел системасы өлкәсендә: сүзнең мәгънәсен аңлау, ситуациядән чыгып, тиешле сүзне таба белү; сүзтезмә, җөмләләр төзи белү, гади җөмлә төзелешендәге хаталарны таба белү; дөрес язу күнекмәләре (өйрәнелгән күләмдә) формалаштыру, матур язу күнекмәләре булдыру (күчереп язу яисә үз фикерен белдерүне таләп иткән биремнәрдә), сүзлек запасын баету.

Математика өлкәсендә: өйрәнелгән бүлекләр буенча белем һәм күнекмәләрне үстерү (сан, арифметик гамәлләр, геометрик күзаллаулар, төрле типтагы мәсьәләләр чишү), текст, таблица формасында бирелгән мәсьәләләрнең биремнәрен аңлап чишә белү, үз гамәлләрен нигезли белү.

Әйләнә-тирә дөньяны танып белү өлкәсендә: табигать объектлары, аларның характерлы билгеләре турындагы беренчел күзаллауларны булдыру, матдә һәм җисем (масса, күләм, тизлек һәм башка характеристикалар), тере һәм тере булмаган табигать объектлары, хайван һәм үсемлекләрнең төрле классына караган аерым бер вәкилләрен тану һәм аларга характеристика бирү, аерым бер географик объектларны тану; системага салу.

Моннан тыш тәкъдим ителгән эшләр системасы рефлексия, җайга сала белү, үзконтроль, үзкоррекция кебек универсаль

гамәл ысулларын булдырырга да ярдәм итә.

Ярдәмлектә мәгълүмат алу, эзләү, алган белемнәрне ныгыту юллары шактый төрле итеп бирелгән һәм алар түбәндәге мәгълүмати уку күнекмәләре формалаштырырга ярдәм итә:

– текстның темасын һәм төп мәгънәсен билгеләү, җөмләдән яисә тексттан тиешле мәгълүматны эзләп табу;

– берничә сүзләр варианты арасыннан куелган бурычка туры килә торганын эзләп табу;

– табылган сүзне төрле график тамга белән билгеләү;

– өлешләре, элементлары, символик билгеләнелешләре буенча сүзне эзләп табу;

– төрле ысуллар белән (сүз, таблица, схема, диаграмма рәвешендә) бирелгән мәгълүматны үзләштерү, таблица структурасында ориентлашу, таблица белән эшли белү, бирелгән схема нигезендә сүзне табу һәм, киресенчә, сүзгә схема төзү;

– ребуслар чишү, анаграммалар төзү.

Мәгълүматны үзгәртү, куллану түбәндәге мәгълүмати уку күнекмәләрен формалаштыра:

– сүзләрне образларга әйләндерү, бер төр мәгълүматны икенче төргә әйләндерү;

– бирелгән сүзләрдә мәгънә табу;

– бирем шарты буенча җөмләләр яки текст төзү;

– терәк сүзләрне дөрес кулланып, текстны уку һәм төшеп калган сүзләрне язып кую;

– тексттан алынган мәгълүматны кулланып, сорауларга җавап бирү;

– текстта бирелгән сүзгә мәгънәсе буенча якын булган икенче сүз табу;

– үрнәк нигезендә таблица төзү;

– билге-символик билгеләнелештә мәгънә табу.

Басмада урын алган комплекслы эшләр нигез һәм катлаулы дәрәҗәдәге биремнәрдән гыйбарәт. Ярдәмлекнең ахырында һәрбер вариантның җаваплары күрсәтелгән, бу исә укучыга үзен бәяләргә мөмкинлек бирә. Биремнәр ике типка берләштерелеп тәкъдим ителде:

1) билгеле бер дәрәҗәдә УУГ формалаштыру максатыннан махсус бирелгән сорау яки биремнәр: когнитив, эмоциональ, эшчәнлекледән башлап, иҗади характердагы биремнәргә кадәр;

2) бер үк вакытта төрле УУГ формалаштыруга ярдәм итә торган күпфункцияле биремнәр.

Ярдәмлектә, беренче чиратта, шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләренә зур урын бирелде. Нәкъ менә беренче сыйныф укучысында игелеклелек, намуслылык, гаделлек, тырышлык, батырлык сыйфатларын булдыру аеруча мөһим. Әхлакый төшенчәләрне формалаштыру, текстның эчтәлегеннән чыгып, биремне үтәгәндә яки сорауларга җавап биргәндә, укучының шәхси позициясен билгеләү аша бара. Тексттагы вакыйгаларга, геройларга карата укучының үз позициясен билгеләү ирекле җавап, текстка исем уйлап табу һәм татар халык авыз иҗаты үрнәкләре белән танышу аша эшләнде.

Ярдәмлектә җавап формасына бәйле рәвештә төрле

характердагы биремнәр урын алган:

– рәсем формасында җавапны сайлап алу;

– бер яки берничә дөрес җавапны сайлап алу;

– сүз формасындагы кыска җавапны тиешле урынга язу;

– текстта төшеп калган сүзләрне язу;

– тулы һәм ирекле җавапны язу;

– эзлеклелекне билгеләү;

– үзара бәйләнешләрне уклар (сызыклар) ярдәмендә күрсәтү;

– хатаны эзләп табу һәм төзәтү һ.б.

Шулай итеп, комплексლы эшләрне үткәрү бер предмет кысаларында алган белем һәм күнекмәләрне башка төр уку ситуацияләренә һәм бурычларына күчерә белү сәләтен формалаштырырга, укучыларның компетентлылык дәрәҗәсен ачыкларга ярдәм итә һәм башлангыч белем бирүдә системалы-эшчәнлекле юнәлешне тормышка ашыруда актуаль форма булып тора.

*Мәкалә «2014–2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасының 3.5.4 номерлы чарасын тормышка ашыру кысаларында нәшер ителә*

**Әдәбият**

*Батырева С.Г.* Типовые задачи по формированию универсальных учебных действий. Литературное чтение. 1 класс: пособие для учащихся общеобразоват. учреждений. М.: Просвещение, 2012. 95 с.

Как проектировать универсальные учебные действия в начальной школе: от действия к мысли / А.Асмолов и др. М.; СПб.: Просвещение, 2008. 151 с.

Метапредметные результаты: Стандартизированные материалы для промежуточной аттестации: 5 класс / Г.С. Ковалёва и др. М.; СПб.: Просвещение, 2014. 160 с.

*Мошнина Р.Ш.* Типовые задачи по формированию универсальных учебных действий. Окружающий мир. 2 класс: пособие для учащихся общеобразоват. организаций. М.: Просвещение, 2013. 79 с.

*Сәгъдиева И.Т.* «Аңлап уку стратегияләре һәм текст белән эш итү» программасы // Мәгариф, 2015. № 12. Б. 14–17.

*Сизонова В.В., Ткаченко М.О.* Комплексная работа – средство формирующего оценивания достижения метапредметных результатов в начальной школе [Текст] // Педагогическое мастерство: материалы VII Междунар. науч. конф. (г. Москва, ноябрь 2015 г.). М.: Буки-Веди, 2015. С. 162–166.

*Хәмитова Г.Р.* Федераль дәүләт башлангыч гомуми белем бирү стандартларын гамәлгә кую мәсьәләләре // Мәгариф, 2015. № 1. 3–7 б.

***Гыйләҗева Лилия Гыйльметдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты доценты*

***Һадиева Гөлнара Васил кызы,***
*Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының өлкән укытучысы*